КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 6 июль г.Казань № 563

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 – 2022 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2016 ел, 10 июнь, 395 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 – 2022 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2016 ел, 10 июнь, 395 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 5 июнь, 342 нче; 2017 ел, 12 сентябрь, 650 нче; 2017 ел, 27 ноябрь, 911 нче; 2018 ел, 14 май, 363 нче; 2018 ел, 24 декабрь, 1211 нче; 2019 ел, 22 июль, 610 нчы; 2020 ел, 27 апрель, 343 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2016 – 2022» саннарын «2016 – 2023» саннарына алыштырырга;

1 нче пунктта «2016 – 2022» саннарын «2016 – 2023» саннарына алыштырырга;

әлеге карар белән расланган «2016 – 2022 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасында (алга таба – Программа):

исемендә «2016 – 2022» саннарын «2016 – 2023» саннарына алыштырырга;

Программа паспортында:

«Программа исеме» юлында «2016 – 2022» саннарын «2016 – 2023» саннарына алыштырырга;

«Программаның дәүләт заказчылары» юлында «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алыштырырга;

«Программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары» юлында «2016 – 2022» саннарын «2016 – 2023» саннарына алыштырырга;

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, финанслау күләмнәре | Программаны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслауның гомуми күләме 1 926 056,1 мең сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:<br>2016 ел – 131 029,4 мең сум;<br>2017 ел – 264 939,7 мең сум;<br>2018 ел – 269 808,0 мең сум;<br>2019 ел – 281 443,9 мең сум;<br>2020 ел – 251 487,6 мең сум;<br>2021 ел – 241 384,7 мең сум;<br>2022 ел – 242 981,4 мең сум;<br>2023 ел – 242 981,4 мең сум.<br>Искәрмә. Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм тиешле финас елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш»; |

«Еллар буенча бүлеп, Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелгән соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар буенча бүлеп, Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелгән соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашыру 2023 елга түбәндәге күрсәткечләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>дәүләт архивлары бина урыннарының архив документларын даими саклауны тәэмин итә торган норматив шартларга туры килүе дәрәҗәсен 99 процентка кадәр арттыруга;<br>иминият күчермәләре булган уникаль һәм аеруча кыйммәтле документлар өлешен 94 процентка кадәр арттыруга;<br>хисап елында алырга планлаштырылган документларның гомуми санында дәүләт архивлары өчен түләүле нигездә алынган документлар өлешен 100 процентка җиткерүгә;<br>Татарстан Республикасының документаль мирасын популярлаштыруга юнәлдерелгән чаралар санын 1 елга өч берәмлеккә кадәр |

| | |
|---|---|
| | җиткерүгә;<br>тануны һәм тасвирлауны таләп итә торган документларның гомуми саныннан фәнни тасвирланган документлар өлешен 80 процентка кадәр арттыруга;<br>үткәрелгән конкурсларның (һөнәри; архив документлары нигезендә; архив эшен популярлаштыру һәм үстерү максатларында) санын 1 елга биш берәмлеккә кадәр ирештерүгә;<br>конкурс нигезендә ярдәм күрсәтүдән файдаланган муниципаль архивлар санын 1 елга 15 берәмлеккә кадәр ирештерүгә;<br>хисап елында планлаштырылган катнашучыларның гомуми санында һөнәри конкурсларда катнашучыларның өлешен 80 процентка кадәр ирештерүгә;<br>бер елда үтәлгән соратуларның гомуми күләмендә архивлар тарафыннан билгеләнгән вакытларда үтәлгән соратулар өлешен 100 процентка кадәр арттыруга;<br>Татарстан Республикасында архив эше белән идарә итүнең бердәм мәгълүмат-аналитика системасына тоташтырылган дәүләт һәм муниципаль архивлар, коммерция оешмалары архивлары – дәүләт архивын комплектлау чыганаклары өлешен аларның гомуми саныннан 100 процентка кадәр арттыруга;<br>«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәме белән аудиовизуаль продукциянең мәҗбүри нөсхәләрен электрон кабул итү һәм тикшерү системасының шәхси кабинетлары аша документларын җибәрә торган оешмалар – аудиовизуаль продукциянең мәҗбүри нөсхәсен җитештерүчеләр өлешен аларның гомуми саныннан 70 процентка кадәр арттыруга;<br>системаның шәхси кабинетлары аша документлар җибәрә торган оешмалар – басма продукциянең мәҗбүри нөсхәсен җитештерүчеләр өлешен аларның гомуми саныннан 50 процентка кадәр арттыруга;<br>Татарстан Республикасының Бердәм архив мәгълүмат системасына кертелгән дәүләт һәм муниципаль архивлар делоларының цифрлаш- |

| | |
|---|---|
| | тырылган һәм индексацияләнгән тасвирлау исемлекләре һәм исемнәре өлешен планлаштырылганнар санынннан 100 процентка кадәр җиткерүгә;<br>аеруча кыйммәтле саклау берәмлекләренең гомуми санынннан, муниципаль берәмлекләрдә ачыклана торганнарын исәпкә алып, цифрлаштырылган аеруча кыйммәтле саклау берәмлекләре өлешен 100 процентка кадәр арттыруга;<br>бобиналарның гомуми санынннан цифрлаштырылган кинопленка бобиналары өлешен 50 процентка кадәр арттыруга;<br>цифрлаштырылган документларның гомуми санынннан бердәм мәгълүматлар саклау системасында саклана торган цифрлаштырылган документлар өлешен 100 процентка кадәр җиткерүгә;<br>стипендия алган стипендиатлар санын 1 елга 43кә кадәр арттыруга;<br>дәүләт һәм муниципаль архивларда модернизацияләнгән эш урыннары өлешен 100 процентка кадәр арттыруга;<br>электрон уку залында булулар санын 3 500 кешегә кадәр арттыруга;<br>яңадан һөнәри әзерләүне, квалификация күтәрүне, стажировканы үткән дәүләт һәм муниципаль архивлар хезмәткәрләре өлешен хисап елында планлаштырылган дәүләт һәм муниципаль архив хезмәткәрләренең гомуми санында 90 процентка кадәр җиткерүгә;<br>әзер муляжларны кулланып, экспонатлаштыру буенча чаралар санын 1 елга өч берәмлеккә кадәр арттыруга;<br>хисап елында дәүләт архивының уку залында аннан файдаланучыларга бирелгән делоларның гомуми санында бирелгән штрихкодлы делолар өлешен 100 процентка кадәр җиткерүгә;<br>модернизацияләнгән һәм кертелгән яңа функциональ модульләр санын 1 елга алты берәмлеккә кадәр җиткерүгә;<br>агымдагы елда планлаштырылган язуларның гомуми санында генеалогия һәм шәҗәрә генеалогик язмалар порталын тулыландыру өлешен 100 процентка кадәр җиткерүгә»; |

I бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«I. Дәүләт программасын тормышка ашыру өлкәсенең, шул исәптән дәүләт программасын хәл итүгә юнәлдерелгән проблеманың тасвирнамәсе

Татарстан Республикасы территориясендә архив эшен үстерү Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, «Россия Федерациясендә архив эше турында» 2004 елның 22 октябрендәге 125-ФЗ номерлы, «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны саклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы, «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы, «Электрон имза турында» федераль закон кабул итүгә бәйле рәвештә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 6 апрелендәге 65-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында архив эше турында» 2017 елның 20 июлендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ведомствоара электрон документлар әйләнеше системалары турындагы, башкарма хакимият органнарының эш башкару кагыйдәләре турындагы, муниципаль берәмлекләр төзелгәнгә, берләшкәнгә, бүленгәнгә яки статусы үзгәргәнгә кадәр булдырылган һәм Татарстан Республикасында муниципаль архивларда саклана торган архив документларына милекне бүлү турындагы норматив хокукый актлары белән җайга салына.

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 24 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы дәүләт милкенә караган һәм муниципаль берәмлекләр территориясендә урнашкан архив документларын саклау, комплектлау, исәпкә алу һәм алардан файдалану буенча аерым дәүләт вәкаләтләре бирелде.

«Документларның мәҗбүри нөсхәсе турында» 1994 елның 29 декабрендәге 77-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсе турында» 2005 елның 18 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт архивы барлык төрләрдәге басмаларның һәм аудиовизуаль продукциянең мәҗбүри бер нөсхәсен алучы булып тора.

1994 елда Татарстан Республикасы Архив хезмәте тулы вәкаләтле әгъза хокукында («А» категориясе буенча) Халыкара архивлар советына кабул ителде.

2003 елда Татарстан Республикасы Архив хезмәте Халыкара архивлар советының Евроазия төбәк бүлеге (ЕВРАЗИКА) әгъзасы булды.

Татарстан Республикасы Архив фонды Россия Федерациясе Архив фондының аерылгысыз бер өлеше, тарихый, сәяси, икътисадый, фәнни, социаль, мәдәни, матди һәм рухи мирасның, халыкның мәгълүмати һәм интеллектуаль байлыгының бер өлеше булып тора.

Татарстан Республикасы архивлары – ул 7,7 млн. саклау берәмлегеннән (шулардан дәүләт архивында – 5,8 млн. саклау берәмлеге, муниципаль архивларда – 1,8 млн. саклау берәмлеге) торган 25 513 фонд. Архив фонды составына 1709 – 2012 еллар өчен 4,3 млн. саклау берәмлеге кертелгән, аерым документларның датасы XI – XVII гасырларга карый.

Советка кадәрге чор документларында Идел буе, Көнбатыш Себер, Казахстан, Төньяк Кавказ тарихы буенча мәгълүматлар бар.

Татарстан Республикасы Архив фонды – Россиядә иң эре фондларның берсе: Ленинград өлкәсе, Мәскәү һәм Түбән Новгород өлкәсе фондларыннан соң зурлыгы буенча дүртенче. Уникаль документларга – дәүләт архивының 21 документы, аеруча кыйммәтле документларга 65 752 саклау берәмлеге кертелгән.

2016 – 2019 еллар дәвамында Татарстан Республикасы Архив фонды күләме – 5 процентка, шул исәптән аудиовизуаль документлар күләме 41 процентка артты. Саклауга сайлап алына торган документларның төр составы киңәйтелде. Моңа шәхси фондларны тотучылар белән эшләүне активлаштыру һәм инициативалы документлаштыру этәргеч ясады. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Архив фонды составына керми торган шәхси состав буенча документлар саны 6 процентка артты.

Документларның гомуми күләменнән кәгазьдә саклана торган документлар – 98,4 процент, аудиовизуаль документлар өлеше 1,4 процент тәшкил итә. 18 846 фондның 4,1 миллионнан артык саклау берәмлеге идарә документларына карый – бу Татарстан Республикасы Архив фондының 96 проценты. Татарстан Республикасы Дәүләт архивының 26 фондында 12 меңнән артык фәнни-техник документ саклана. Республиканың дәүләт һәм муниципаль архивларында 121,5 меңнән артык фото-, фоно-, видеодокумент, 352 фондта – 26 242 шәхси чыгышлы дело саклана. Дәүләт һәм муниципаль архивларда 6 289 фондта ябылган оешмаларның шәхси составы буенча 1,3 миллионнан артык дело саклана (саклана торган документларның гомуми күләменнән 17,3 процент).

Электрон документ әйләнешен үстерү һәм оешмаларның эш башкару практикасында электрон документларны арттыру Татарстан Республикасы Архив фонды составының төре эзлекле үзгәрүенә объектив рәвештә китерергә тиеш. Шуңа күрә архивларны электрон документларны кабул итүгә, саклауга һәм файдалануга, аларның аутентиклыгын тәэмин итүгә әзерләү – архив эшен үстерүнең өстенлекле юнәлеше.

Комплектлау чыганакларының составы яңадан каралды һәм киңәйтелде, шартнамә нигезендә дәүләткә карамаган оешмалар һәм шәхси фонд тотучылар белән хезмәттәшлеккә аерым игътибар бирелде. Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының эксперт-тикшерү һәм методик комиссиясе чыганакларның җыелма исемлеген тулыландыру – Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль архивларын комплектлау һәм документларны сыйфатлы итеп сайлап алу мәсьәләләрен планлы рәвештә хәл итте.

Муниципаль архивлар өлешенә республика архивларында саклана торган документларның гомуми күләменнән 23,3 процент, Татарстан Республикасының архив учреждениеләрен комплектлау чыганакларының – учреждениеләрнең 80 процентыннан һәм архив эше өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең

80 процентыннан күбрәге туры килә. Татарстан Республикасы Архив фондының муниципаль архивларда саклана торган документларының гомуми күләменнән 17,8 процентын Татарстан Республикасы дәүләт милкенә караган документлар тәшкил итә.

Саклана торган документларның күләме буенча Татарстан Республикасы муниципаль архивлары Идел буе федераль округы төбәкләренең профильле архивлары арасында Түбән Новгород өлкәсе, Башкортостан Республикасы, Пермь крае һәм Саратов өлкәсеннән кала бишенче урынны алып тора.

Ел саен кабул ителә торган идарә документлары саны буенча республиканың муниципаль архивлары – алтынчы позициядә, шәхси чыгышлы документларны һәм фотодокументларны кабул итү буенча унынчы һәм тугызынчы урыннарда тора.

Татарстан Республикасының муниципаль архивлары фондларында чагыштырмача аз күләмдә аудиовизуаль документлар, шәхси чыгышлы документлар бар, фәнни-техник документлар ачыкланмады.

Муниципаль архивлар дәүләт архивларына караганда электрон мәгълүматлар йөртү җайланмаларында идарә документларын кабул итү проблемасы белән очрашачак, чөнки архив законнары нигезендә муниципаль милеккә караган документлар, биш ел үткәннән соң, җирле архивларга даими саклауга бирелә.

Муниципаль архивларны комплектлауда ел саен комплектлау чыганакларында – оешмаларда барлыкка килә торган даими саклау документлары күләме арту тенденциясе күзәтелә, шулай ук Татарстан Республикасы Архив фонды документларыннан шәхси состав буенча кабул ителә торган документлар күләме артып китә. Ябылган оешмаларның шәхси состав буенча документларының зур күләме ел саен Казан шәһәре муниципаль архивы, Яр Чаллы шәһәренең шәхси состав буенча документлар архивы, шулай ук Әлмәт, Зәй, Зеленодольск, Лениногорск, Түбән Кама, Чистай шәһәрләре территориясендә урнашкан муниципаль архивлар тарафыннан кабул ителә. Шәхси состав буенча документлар күләме Зәй, Казан, Түбән Кама, Чистай архивларында Татарстан Республикасы Архив фонды документларыннан артып китә. Шәхси состав буенча документларның зур күләме – Әлмәт, Зеленодольск, Лениногорск архивларында.

Стеллаж киштәләренең озынлыгы (погонлы метрларда): дәүләт архивында – 57 386; муниципаль архивларда – 37 141. Барлык биналарның архив саклагычлар мәйданы: дәүләт архив саклагычларның – 9 399,02 кв.метр, муниципаль архив саклагычларның – 763 688 кв.метр тәшкил итә.

Республика дәүләт архивы биш бинада урнашкан, шуларның дүртесе җайлаштырылган, берсе махсуслаштырылган. Муниципаль архивлар 51 җайлаштырылган бүлмәдә урнашкан.

Дәүләт һәм муниципаль архивларның архив саклагычларында архив документларын саклау (һаваны кондиционерлау, янгын куркынычсызлыгы, аларны урнаштыру) системаларын һәм чараларын даими модернизацияләргә кирәк.

Дәүләт архивларында мәгълүмат йөртү җайланмасы һәм тексты бозылган 14 475 саклау берәмлеге исәптә тора. Дәүләт архивының мөмкинлекләре реставрация эшләре күләмен арттырырга мөмкинлек бирми. Кинопленкаларның физик торышын тикшерү эшен даими үткәрү кирәклеге бар, ә консервация-профилактика эшләре, акча керүгә карап, даими рәвештә гамәлгә ашырыла.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Дәүләт архивында яна торган нитронигездә 160тан артык саклау берәмлеге кинодокумент саклана. Вакытлар узу белән пленканың химик составы дарыга эквивалент була, бу үз-үзен яндыруга китерергә мөмкин. Документлар мәгълүматларын температура режимы +10°С (кара-ак), -5°С (төсле), чагыштырмача дымлылык 40 – 50 процент булган бокста саклауны тәэмин итәргә кирәк. Нитронигездә булган пленка яна башлаганда кислородсыз пыскылдап яна һәм аны сүндереп булмый диярлек. Мондый пленкаларны иң оптималь саклауны сәнәгать суыткыч җайланмаларында башкарырга була.

Моннан тыш, хәзерге вакытта рулонлы пленкадагы, микрофишалардагы кинопленкаларның һәм микрофильмнарның серкә синдромы проблемасы бар. Саклап калуның бердәнбер ысулы – ул мәгълүматны цифрлы мәгълүмат йөртү җайланмаларына күчерү, бу җиһаз, мәгълүмат йөртү җайланмалары сатып алу һәм хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү өчен өстәмә матди чыгымнар таләп итә.

Кәгазьдә дә, пленкада да булган архив документларына яный торган күгәрәк архив документларын саклауның зур проблемасы булып тора. Документларны даими эшкәртеп торырга кирәк. Мәсәлән, консервация-профилактика эшкәртүен үткәрмәгән очракта, күгәрек гөмбәсе кинопленканы берничә ай дәвамында юкка чыгарырга мөмкин.

Республика дәүләт һәм муниципаль архивларының янгын һәм саклау куркынычсызлыгын даими ныгыту, температура-дымлылык режимын үтәү, документларны саклау өчен кирәкле санда мәйданнар белән, шул исәптән саклау системасын модернизацияләү хисабына тәэмин итү таләп ителә.

Сакланышны тәэмин итү чаралары системасында документларның алардагы мәгълүматны саклау мөмкинлеген бирә торган иминият күчермәсен ясау аерым урын алып тора. Моннан тыш, бер үк вакытта позитив пленкада булдырыла торган файдалану фонды аеруча кыйммәтле документларның төп нөсхәләрен файдаланудан алуны тәэмин итә диярлек. Архивларда документларны цифрлаштыру таралганнан тарала бара, бу документларны яңадан торгызуның һәм мәгълүматны төп нөсхәләргә мөрәҗәгать итмичә файдалануның яңа мөмкинлекләрен һәм киң перспективаларын ача. Бу эшне активлаштыру өчен архивларга тиешле техника сатып алырга кирәк.

Татарстан Республикасы Дәүләт архивы автоматлаштырылган фәнни-белешмә аппаратын, нигездә, тематик мәгълүматлар базасы рәвешендә булдыру буенча эш алып бара. Документларны тасвирлау күләме иң күбе 10 процент тәшкил итә. Бу мәгълүматларның бары бер өлешеннән генә онлайн-режимда файдаланырга мөмкин. Үткән заманда булуга карамастан, Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль архивларында фәнни-белешмә аппаратының торышы, элеккечә, оператив актуальләштерүне һәм архив фондларының фәнни-белешмә аппаратын һәм коллекцияләрне электрон рәвешкә күчерүне таләп итә.

Бердәм мәгълүмат-аналитика системасын булдыру һәм үстерү архив учреждениеләренең ачык булуын арттыруга китерәчәк, заманча мәгълүмат технологияләрен куллану нигезендә архив документларыннан һәркем файдалана алу мөмкинлеген һәм файдалану нәтиҗәлелеген арттырырга, профильле функцияләрнең үтәлешен оптимальләштерергә һәм архив фондларын исәпкә алуны, саклауны һәм алар белән идарә итүне автоматлаштыруны сыйфатлы яңа дәрәҗәгә чыгарырга мөмкинлек бирәчәк.

Моннан тыш, бердәм мәгълүмат-аналитика системасын булдыру гамәлдәге эш башкаруларны һәм хезмәт күрсәтүләрне түләүле нигездә үтәү һәм яңаларын кертү өчен ярдәм булыр иде.

Хакимият органнары, оешмалар, учреждениеләр һәм физик затлар ягыннан Татарстан Республикасы Архив фондының ретроспектив мәгълүматларына мөрәҗәгатьләр агымы даими артып бара. Мөгаен, социаль-хокукый һәм тематик соратулар саны арта бару һәм архив фондларының күләмен даими арттыру шартларында документлар белән традицион формада эшләү түбәндәге факторлар белән катлауланачак:

документларны һәм делоларны бер үк вакытта берничә кулланучы тарафыннан (архив хезмәткәрләре дә, архивларның уку залында булучылар да) файдалану мөмкинлеге булмау;

документларның тиз искерүе югары дәрәҗәдә ихтимал булу.

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтүгә күчү оперативлыкны арттырачак, хезмәтләр күрсәткәндә максималь сыйфатны тәэмин итәчәк һәм гражданнар өчен уңайлы шартлар булдырырга, шулай ук коррупция фактлары килеп чыгу рискын минимальләштерегә мөмкинлек бирәчәк.

Хәзерге вакытта республиканың дәүләт һәм муниципаль архивларында архив документларының 191 654 саклау берәмлеге цифрлаштырылган, бу Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль архивларында саклана торган архив документларының гомуми күләменнән 4,5 процент тәшкил итә.

Моннан тыш, дәүләт архивында 25 584 архив документының тасвирлау исемлеге цифрлаштырылган. Кулланучыларның архив документларының тасвирлау исемлекләрен эзләвен һәм алар белән нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү өчен аларны индексацияләргә кирәк – бу күп көч һәм озак вакыт таләп итә торган процесс. Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль архивларында бүгенге көндә 46 872 архив документының тасвирлау исемлеге бар, аларда 5,5 млн. саклау берәмлеге тасвирланган.

Татарстан Республикасы Архив фонды документлары социаль һәм фәнни-агарту максатларында киң кулланыла.

Гражданнардан, шулай ук кызыксынучы оешмалар һәм учреждениеләрдән керә торган социаль-хокукый соратуларны башкару архив эшчәнлегенең төп юнәлешләреннән берсе булып тора. 2019 елда дәүләт һәм муниципаль архивлар тарафыннан 98 283 сорату, шул исәптән 83 992 социаль-хокукый характердагы сорату, 11 917 тематик сорату һәм 2 374 генеалогия буенча сорату үтәлде. Архивларның уку залларында 1 099 кулланучы булды. Архивларга соратулар төрле чыганаклардан: интернет-кабул итү бүлмәсе, электрон почта, VipNet программа комплексы, почта элемтәсе аша, шәхси кабул иткәндә керә.

Татарстан Республикасы архивлары тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын яхшырту һәм һәркем файдалана алу мөмкинлеген арттыру, шул исәптән хезмәтләр күрсәтүне электрон төргә күчерү – ул өстенлекле бурыч булып тора.

Дәүләт структуралары өчен архивлар – идарә документларын саклау урыны һәм документаль мәгълүматлар белән идарә итү системасында экспертлар.

Фәнни җәмәгатьчелек вәкилләрен темаларның иң киң спектры һәм иң киң хронология кызыксындыра. Архивчылар һәм гуманитария галимнәре арасында архив документларын өйрәнү, бастырып чыгару һәм күрсәтү өлкәсендә, кадрлар әзерләү өлкәсендә традицион рәвештә тыгыз хезмәттәшлек бар.

Безнең документлар мирасны өйрәнү һәм популярлаштыру өлкәсендә тикшеренүчеләр белән хезмәттәшлекне арттырырга кирәк.

Бу тема Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү турында» 2015 елның 25 сентябрендәге 930-ПУ номерлы Указын тормышка ашыру контекстында аеруча актуаль булып тора.

Республиканың дәүләт һәм муниципаль архивларына, үз чиратында, фәнни берләшмә белән киңрәк хезмәттәшлек итәргә кирәк. Өстәвенә, бик нык фәнни кызыксыну уята торган документлар да бар, архивчылар аларны үз көчләре белән билгели алмыйлар. Болар – Татарстан Республикасы Дәүләт архивында саклана торган гарәп, фарсы, монгол, тибет, кытай телләрендәге кульъязмалар.

Аларны үз илебез һәм чит ил галимнәре белән кооперацияләүдә фәнни әйләнешкә кертү тарихның яңа битләрен ачарга гына түгел, ә Россиянең бердәм мәдәни киңлеген ныгытырга, республика архивчыларының халыкара фәнни элемтәләрен ныгытырга да мөмкинлек бирер иде.

2015 елда республика архивчылары «Гасырлар авазы – Эхо веков» фәнни-документаль журналын Россия Федерациясе Фән һәм югары белем бирү министрлыгы каршындагы Югары аттестация комиссиясенең рецензияләнә торган фәнни басмалары исемлегенә кертүгә иреште.

Республика архивчылары ел саен Казан мәктәпләрендә Бөек Ватан сугышында Җиңү көненә багышланган батырлык дәресләре үткәрә. Чын документлар белән танышу һәрвакыт укучыларда зур тәэсир калдыра.

Фәнни җәмәгатьчелек белән хезмәттәшлек итүдә өстенлек булып фәнни һәм тарихый-мәдәни әһәмияткә ия булган документларның сакланышын һәм сыйфатлы туплануын тәэмин итү тора. Бу эштә һәркем файдалана алу мөмкинлеген арттыру максатларында документаль мирасны цифрлаштыру мөһим әһәмияткә ия.

Дәүләт һәм муниципаль архив хезмәтләре хезмәткәрләренең саны 300дән артык кеше тәшкил итә. Министрлыкларда һәм ведомстволарда архивларны алып баруны 108 кеше тәэмин итә. Моннан тыш, архивлар бик күп эре сәнәгать предприятиеләрендә, югары уку йортларында, фәнни-тикшеренү институтларында бар.

2020 елның 1 гыйнварына архив учреждениеләрендә 0,3 процент пенсия яшендәге хезмәткәрләр, 50 яшьтән алып пенсия яшенә кадәр – 18,9 процент, 30 яшьтән алып 49 яшькә кадәр – 45 процент, 29 яшькә кадәр (29 яшьне кертеп) 23,9 процент эшләде.

Архив учреждениеләрендә хезмәткәрләрнең гомуми санынннан эш стажы: 15 елдан артык – 15,8 процент; 11 елдан 15 елга кадәр – 12,1 процент; 6 елдан 10 елга кадәр – 14,5 процент; 1 елдан 5 елга кадәр – 34,1 процент; 1 елга кадәр – 11,1 процент.

Архив эше өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең нәтиҗәлелегә, эшчәнлек нәтиҗәләре шактый дәрәҗәдә кадрлар потенциалына, аның һөнәри дәрәҗәсенә, әзерлек сыйфатына бәйле.

Архив эшенең алга таба үсеше алдагы елларда эшләп тупланган традицион мәгълүмат йөртү җайланмаларда документлар, заманча технологияләр белемнәре белән эшләү тәҗрибәсен синтезлаудан башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Бу дәүләт архивы хезмәткәрләренең кадрлар составын ныгыту, аларның социаль яклануын арттыру, профильле уку йортларын тәмамлаучыларны архивларга җәлеп итү кирәклеген күздә тота. Кадрлар проблемасын хәл итү өчен архив тармагындагы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең эш хакын Татарстан Республикасы буенча уртача хезмәт өчен түләү дәрәҗәсенә җиткерү таләп ителә, бу архивчылар эшенең абруен күтәрергә, хезмәт коллективларының тотрыклылыгын һәм аларның һөнәри осталыгын арттыруны тәэмин итәргә, Россия Федерациясе субъектларының архив учреждениеләре, гуманитар профильдәге югары уку йортлары, Документ белеме һәм архив эше буенча бөтенроссия фәнни-тикшеренү институты белән Россия һәм чит ил архивларында белгечләрнең стажировкасын һәм җитештерү практикасын үткәрү мәсьәләләрендә тыгыз хезмәттәшлек итү юлы белән кадрларны яңадан әзерләү һәм аларның квалификацияләрен күтәрү эшен дәвам итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Архив тармагының кадрлар потенциалын үстерү максатларында төрле эш формаларын куллану күздә тотыла: һөнәри осталык курслары, тренинглар, проблемалар буенча семинарлар, түгәрәк өстәлләр.

Татарстан Республикасында архив тармагының торышын төрле яклап өйрәнү һәм чишелешне таләп итә торган проблемаларны ачыклау максаты белән SWOT методикасы буенча архив эшен үстерүгә стратегик анализ ясалды, аның нәтиҗәләре 1 нче таблицада китерелде.

1 нче таблица

Татарстан Республикасында
SWOT-архив тармагы үсешенә анализ

| Көчле яклары (S) | Йомшак яклары (W) |
| --- | --- |
| Татарстан Республикасының социаль-икътисадый, фәнни, инновацион потенциалы архив тармагының нәтиҗәле үсеше өчен шартлар тудырырга сәләтле.<br>Идел буенда иң бай архивлардан берсе булган Татарстан Республикасы Архив фондының бай мәгълүмат потенциалы бар, ул үз эченә идарә, фәнни-техник документларны, шәхси чыгышлы документларны, шәхси состав буенча документларны, традицион булмаган мәгълүмат йөртү җайланмаларындагы | Архив эше өлкәсендәге законнар тармак үсеше ихтыяҗларына тулысынча җавап бирми.<br>Документларның күчермәләрен саклау һәм ясау, реставрацияләү, консервация-профилактика эшкәртүен үткәрү өчен буш мәйданнар, махсуслаштырылган биналар булмау.<br>Республика архивлары матди-техник базаны үстерүгә, шул исәптән компьютер паркын даими яңартуга, программа тәэминатын сатып алуга мохтаҗ. |

| | |
|---|---|
| (аудиовизуаль, электрон) документларны, басма һәм аудиовизуаль продукциянең мәҗбүри нөсхәләрен ала.<br>Документаль мәгълүмат ресурслары дәүләтнең һәм җәмгыятьнең ретроспектив мәгълүматларга булган ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында, шул исәптән гражданнарның конституциячел хокукларын тормышка ашыру өчен дә актив кулланыла.<br>Аудиовизуаль мәгълүматны саклау һәм файдалану өлкәсендә яңа технологияләрне кертүнең уңай тәҗрибәсе булу һәм бу тәҗрибәне башка төбәкләргә таратуга әзер булу.<br>Алга таба үсеш потенциалы булган архив хезмәткәрләренең тәҗрибәле кадрлары булу.<br>Муниципаль берәмлекләр белән Татарстан Республикасында архив эшен оештыруның бердәм принципларын саклап калуны һәм кертүне, муниципаль архивларга аларның эшчәнлегендә методик һәм практик ярдәм күрсәтүне тәэмин итә торган традицион элемтәләрне саклау | Бүлеп бирелә торган финанслау күләме архив тармагының эшләвен һәм үсешен тулысынча тәэмин итәргә мөмкинлек бирми.<br>Мәгълүматлаштыру өлкәсендәге эшчәнлекне кадрлар белән тәэмин итүнең торышы канәгатьләндерерлек булмау: архивларда IT-белгечләр җитмәү, кадрлар картаю, дәүләт архивында эш хакы дәрәҗәсе түбән булу, бу архив тармагыннан яшь белгечләрнең китүенә сәбәп булып тора.<br>Профильле белеме булган муниципаль архивлар хезмәткәрләренең саны аз булу.<br>Муниципаль берәмлекләрдә шәхси состав буенча махсуслаштырылган архивлар (Яр Чаллы шәһәренең шәхси состав буенча архивыннан тыш) булмау (бюджет, казна учреждениеләренең оештыру-хокукый формасы белән), муниципаль архивларда кадрлар җитмәү |
| Үсеш мөмкинлекләре (O) | Тышкы янаулар мөмкин булу (T) |
| Татарстан Республикасы Архив фондының мәгълүмат потенциалы үсү.<br>Республика территориясендә Татарстан Республикасының эре инновацион проектларны тормышка ашырырга мөмкинлек бирә торган IT-потенциалы югары булу.<br>Тармакның инновацион социаль-юнәлешле үсешен мәгълүмат-коммуникация технологияләрен киң кулланышка кертү нигезендә тәэмин итү.<br>Архивлар биналарының уңайлы инфраструктурасы һәм урнашуы кулланучының файдалану мөмкинлеге логистикасын кирәкле дәрәҗәдә тәэмин итәчәк.<br>Тармакта күрсәтелә торган хезмәтләр спектрын киңәйтү, электрон форматта күрсәтелә торган хезмәтләрне кулланыш- | Законнар белән җайга салуның камил булмавы һәм цифрлы контентның юридик әһәмиятен раслау буенча суд практикасының төрлелеге.<br>Төзелә торган электрон документларның дөреслеген раслый торган электрон-цифрлы имза сертификатларының кыска вакытлы булуы.<br>Илдә финанс кризисы күренешләренә бәйле булган тотрыксыз икътисадый вәзгыять һәм архив тармагы эшчәнлеген финанслау дәрәҗәсе кимү.<br>Мәйданнар җитмәү сәбәпле, архивларның туплануы туктатылу аркасында ведомство саклау этабында архив документларын югалту рискы.<br>Янгын чыгу куркынычы, гадәттән тыш хәлләр, шулай ук әйләнә-тирә мохитнең |

| | |
|---|---|
| ка кертү.<br>Татарстан Республикасы архив тармагы тарафыннан нәшер ителә торган «Гасырлар авазы – Эхо веков» фәнни-документаль журналы Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы Югары аттестация комиссиясе тарафыннан төзелгән, фәннәр кандидаты гыйльми дәрәҗәсен алуга, фәннәр докторы гыйльми дәрәҗәсен алуга диссертацияләрнең төп фәнни нәтиҗәләре басылып чыгарга тиеш булган рецензияләнә торган фәнни басмалар исемлегенә кертелүенә бәйле рәвештә, фәнни җәмәгатьчелек белән хезмәттәшлекне киңәйтү | архив документларын кире кайтарып булмый торган югалтуга китерә торган деструктив факторлары барлыкка килү |

Институцион характердагы проблемаларны хәл итү буенча Программада бәян ителә торган алымнарның һәм тәкъдимнәрнең функциональ анализ инструменты буларак институциональ матрица кулланыла. Аның структурасы 2 нче таблицада китерелде.

2 нче таблица

Институцион матрица

| Институцион факторлар | Икътисадый эшчәнлек төрләре | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | дәүләт һәм муниципаль идарә | сәнәгать җитештерүе | төзелеш | социомәдәни өлкә | IT-сектор | банк һәм башка финанс хезмәтләре | торак-коммуналь хуҗалык | фән | кече һәм урта бизнес |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| Идарә итү мәгълүматының бердәм мәгълүмат ресурсы булмау | 4 | 5 | 4 | 4 | 4 | 3 | 4 | 5 | 5 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Документларны саклау буенча эшчәнлекне җайга салу мәсьәләләренең ведомство тарафыннан таркалган булуы | 2 | 3 | 4 | 4 | 3 | 2 | 4 | 4 | 5 |
| Архив документларын саклау шартлары тиешенчә булмау, мәйданнарга кытлык булу | 4 | 4 | 5 | 4 | 4 | 4 | 5 | 5 | 5 |
| Цифрлы мәгълүмат йөртү җайланмалары бозылудан саклану дәрәҗәсе түбән булу | 5 | 5 | 5 | 5 | 5 | 5 | 5 | 5 | 5 |
| Документларны саклау һәм архив фондын туплау методологиясе камил булмау | 4 | 5 | 5 | 4 | 5 | 4 | 5 | 5 | 5 |
| Эш башкару һәм архив эше өлкәсендә квалификацияле кадрлар дефициты | 5 | 5 | 5 | 5 | 5 | 5 | 5 | 5 | 5 |

Рейтинг биш баллы шкала буенча, проблематиканың арта баруы буенча үткәрелде.

Матрица баганалары икътисад секторларын һәм эшчәнлек төрләрен чагылдыра. Матрицаның юллары Программаның тиешле бүлекләрендә анализы китерелгән институциональ факторларны билгели. Матрица элементлары икътисадның теге яки бу секторларында һәм эшчәнлек төрләрендә институциональ характердагы җитди проблемалар булуын характерлый.

Санап үтелгән институциональ факторлар идарә карарларын кабул иткәндә институциональ тозаклар барлыкка килүнең максималь рискы һәм куркыныч янаулары зоналарын идентификацияләү принцибы буенча сайлап алынды, кагыйдә

буларак, аларга игътибар кимегәннән соң, алар элеккеге хәленә кайта, ә кайвакыт бу секторлардагы проблемалар кискенләштерә.

Архив эше өлкәсендә хәл ителергә тиешле түбәндәге проблемалар билгеләнде:

керә торган документларның күләме даими артып тору шартларында дәүләт һәм муниципаль архивларның гамәлдәге архив саклагычлары артык тыгыз булу һәм буш мәйданнар җитмәү. Бүлмәләрнең норматив саклау режимнарына туры килмәве;

мәгълүмат йөртү җайланмалары бозылуга бәйле рәвештә, архив документларын югалту рискы югары булу (бетә торган текстлар, кәгазь, пленка таркалу, цифрлы мәгълүмат йөртү җайланмалары бозылу);

Татарстан Республикасының архив киңлегендә бердәм мәгълүмат-коммуникация платформасы һәм аңлаешлы навигация системасы булмау;

электрон документларны һәм электрон мәгълүмат йөртү җайланмаларындагы документларны саклау үзәге булмау;

архивлардагы матди-техник һәм методологик базасының цифрлы контент белән эшләүгә җайлашуы түбән булу, цифрлы контентның сакланышын тәэмин итү һәм дөреслеген раслау методологиясе булмау, махсуслаштырылган җиһаз булмау;

дәүләт архивларында аеруча актив яшьтәге квалификацияле белгечләр китүгә, тәҗрибәле, югары квалификацияле кадрлар картаюга, архивчыларның һөнәри дәрәҗәсе кимүгә бәйле рәвештә кадрлар вәзгыяте катлаулы булу, бу аларның социаль яктан начар якланган булуына шактый дәрәҗәдә бәйле; муниципаль архивлар хезмәткәләренең штат саны тиешенчә булмау.»;

II бүлекнең ундүртенче абзацында «2016 – 2022» саннарын «2016 – 2023» саннарына алыштырырга;

III бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программаны тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү законнар белән билгеләнгән тәртиптә бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчасын файдалануны күздә тота.

Программаны финанслауның гомуми күләме 1 926 056,1 мең сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:

2016 ел – 131 029,4 мең сум;
2017 ел – 264 939,7 мең сум;
2018 ел – 269 808,0 мең сум;
2019 ел – 281 443,9 мең сум;
2020 ел – 251 487,6 мең сум;
2021 ел – 241 384,7 мең сум;
2022 ел – 242 981,4 мең сум;
2023 ел – 242 981,4 мең сум.

Программаны тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү фараз характерында һәм аңа, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.»;

Программаның IV бүлегендәге өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«квартал саен, хисап чорыннан соң киләсе торган айның 10ысына кадәр, Программаны тормышка ашыру турында, шулай ук, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь 1199 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибенә теркәлгән 5 нче кушымта нигезендә Программаны тормышка ашыру турындагы хисап формасын тутырып, финанс чараларын файдалану нәтиҗәлелеге турында статистик, белешмә һәм аналитик мәгълүматны Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына кертә;»;

Программага теркәлгән кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы<br>
Премьер-министры А.В.Песошин